**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**16 май, 2022 ел** **№ 164**

**Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфалар биләүче затларның, аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 31 мартындагы 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон (2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә), Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турындагы Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» Указы, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфалар биләүче затларның, аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 31 мартындагы 47 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфалар биләүче затларның, аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм

әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә, 6 абзацны түбәндәге редакциядәге бәян итәргә:

«г) алар хисабына җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлары), цифрлы финанс активларын, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр гамәлгә ашырылган (алыш-биреш гамәлгә ашырылган) акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең суммасы (мондый алыш-биреш суммасы) хезмәткәрнең (эшләүченең) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда гомуми керемennән артып китсә.».

2. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров